ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)

# КАРАР

икенче утырыш

**09 октябрь 2020 ел** **№ 9** **Теләче авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендә кабул ителгән 124 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлар, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 июлендәге 658 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар** итте:

1.«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы Теләче муниципаль районы Советы карарына (Советның 24.08.2018 № 136, 20.11.2019 № 209 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.».

1.2. Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Советы карарына
2 номерлы кушымта

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының контроль-хисап органнары рәисләренә айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазифа исемнәре | Коэффициентлар |
|---|---|
| | 8 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 30 442 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 27 398 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 27 398 |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов